Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

18 май, 2023 ел № 238

2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында

Муниципаль милеккә идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2009 елның 27 апрелендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы, 2021 елның 30 мартындагы 155 номерлы карарлар белән расланган үзгәрешләр белән) ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планнарын (программаларын) эшләү һәм федераль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турында карарлар әзерләү һәм кабул итү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 26 декабрендәге 806 номерлы карарына (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) үзгәрешләр кертүне исәпкә алып, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 декабрендәге 806 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 2352 номерлы карарын исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. 2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның кушымта итеп бирелә торган Фараз планын (программасын) расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына 2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә йөкләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары белән расланган
18.05.2023 ел № 238

# 2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)

## 1. Гомуми нигезләмәләр

2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2009 елның 27 апрелендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмә (2019 елның 5 декабрендәге 239 номерлы, 2017 елның 29 декабрендәге 124 номерлы карарлар белән расланган үзгәрешләр белән) нигезендә эшләнде.

Хосусыйлаштыру объектларын сатуның башлангыч бәясе «Россия Федерациясенең бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә билгеләнгән базар бәясеннән чыгып билгеләнә.

Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның төп бурычы муниципаль милек структурасын Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнары вазыйфаларын (вәкаләтләрен) һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнмәгән муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру исәбенә оптимальләштерү.

Хосусыйлаштыруның төп максатлары түбәндәгеләр:

- тулаем Питрәч муниципаль районы икътисадының һәм аерым хуҗалык субъектлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;
- муниципаль милек объектларын тотуга җирле бюджет чыгымнарын киметү;
- Питрәч муниципаль районы икътисадын һәм аның инфраструктурасын үстерү өчен инвестиция чараларын җәлеп итү;
- муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырудан акчалар исәбеннән җирле бюджетны тулыландыру;
- җәлеп ителгән акчалар, шулай ук муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырудан алынган акчалар исәбеннән муниципаль ресурсларны торгызу;
- Питрәч муниципаль районы территориясендә эшкуарлык эшчәнлеген үстерүгә һәм бизнесны озак сроклы үстерүгә һәм яңа эш урыннары булдыруга юнәлтелгән нәтиҗәле милекчеләр формалаштыруга ярдәм итү.

2023-2025 елларга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы) гамәлдә булу срогы дәвамында аңа Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарлары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелергә мөмкин.

Ел дәвамында хосусыйлаштырылмаган муниципаль милек объектлары киләсе елга фаразлау планына кертелә.

## 2. 2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

| № п/п | Урыны | Мөлкәт исеме | Мәйданы, кв. м | Хосусыйлаштыруның күздә тотыла торган срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Татар Казысы авыл җирлеге, Татар Казысы авылы, Үзәк ур, 4 | Билгеләнеше: торак булмаган бина; исеме: балалар бакчасы 16:33:000000:1857 | 155,1 | 3-4 квартал 2024 |
| 2 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Пимәр авыл җирлеге, Юныс авылы | Билгеләнеше: торак булмаган бина; исеме: дуңгыз абзары 16:33:130201:52 | 716,4 | 2 квартал 2024 |
| 3 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Пимәр авыл җирлеге, Юныс авылы | Билгеләнеше: торак булмаган бина; исеме: дуңгыз абзары 16:33:130201:59 | 838,9 | 2 квартал 2024 |
| 4 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Татар Казысы авыл җирлеге, Татарн Казысы авылы, Комсомол ур., 172 | Билгеләнеше: торак булмаган бина; исеме: Татар Казысы ФАПы 16:33:110102:118 | 60,9 | 3-4 квартал 2024 |
| 5 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кибәк Иле Авылы, Яңа ур., 4 | Билгеләнеше: торак булмаган бина; исеме: Кибәк Иле ФАП бинасының бер өлеше 16:33:220101:174 | 1 174,3 | 1 квартал 2025 |
| 6 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Янсуар авыл җирлеге, Талкыш авылы, Кооператив ур., 69 | Билгеләнеше: торак булмаган бина; исеме: авыл мәдәният йорты 16:33:190201:66 | 132,4 | 4 квартал 2023 |

| № | Исеме һәм урыны | Устав капиталы, сум. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы устав капиталында муниципаль берәмлек өлеше, процентлар | Хосусыйлаштыруга планлаштырылган акцияләр саны | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | данә | Устав капиталы проценты |
| 1 | «Ак Барс кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Ленино-Кокушкино авылы | 844376884,37 | 0,01032 | 87165 | 0,01032 |

| № п/п | Урыны | Мөлкәт исеме | Чыккан вакыты | Хосусыйлаштыруның күздә тотыла торган срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Питрәч авылы | Автотранспорт чарасыУАЗ-220692-04 автобус | 2002 | 3 - 4 квартал 2023 |
| 2 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Питрәч авылы | Автотранспорт чарасы CHEVROLET NIVA 212300-55 | 2013 | 3 - 4 квартал 2023 |
| 3 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Питрәч авылы | Автотранспорт чарасы CHEVROLET NIVA 212300-55 | 2014 | 3 - 4 квартал 2023 |
| 4 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Питрәч авылы | Автотранспорт чарасы CHEVROLET NIVA 212300-55 | 2016 | 3 - 4 квартал 2023 |
| 5 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Питрәч авылы | Автотранспорт чарасы CHEVROLET NIVA 212300-55 | 2018 | 3 - 4 квартал 2023 |
| 6 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Питрәч авылы | Автотранспорт чарасы FIAT DOBLO | 2011 | 3 - 4 квартал 2023 |
| 7 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Питрәч авылы | Автотранспорт чарасы FIAT DUCATO | 2010 | 3 - 4 квартал 2023 г |